ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ СОВЕТЫ

КАРАР №22

Урыссу ш.т.п.

26.09. 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 23.12.2019 № 23 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советы карар кабул итә:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 23.12.2019 № 23 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип саклау кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Кагыйдәләрнең 15.11.3. пункты н пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«н) әгәр бу Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, тиешле тәртиптә төзелгән һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләрен урнаштыру турында карар кабул иткән милекчеләрне исәпкә алмаганда, теләсә кайсы сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләрен, шул исәптән палаткаларны, киоскларны, кибетләрне, мини-базарларны, павильоннарны, җәйге кафеларны, җитештерү объектларын, автомобильләрне, көнкүреш техникасын, аяк киемен вак ремонтлау предприятиеләрен, шулай ук автостоянкаларны урнаштырырга, кунак автотукталышыннан тыш;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый

мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:// jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Урыссу шәһәр
тибындагы поселогы башлыгы урынбасары Р.М. Гарипов